**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы һәм 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) турында нигезләмәнең 12 пунктында «Утырышта тавыш бирү хокукы булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) Комитет составында:

Комитет составыннан И.С. Бугаковны, В.М. Гуреевны, В.И. Солозобовны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Гарипов Алексей Олеговичны – «Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыятенең идарәче директоры урынбасары – тәҗрибә-конструкторлык бюросы баш конструкторын (килешү буенча);

Найшулер Борис Иосифовичны – «Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының конструкторлык үзәге конструкторлык бюросы директорын (килешү буенча);

Стинский Герман Владимировичны – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең фәнни-инновация бүлеге баш белгечен;

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Н. Карповның – «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Э.В. Шәмсетдиновның – «Казан дәүләт энергетика университетының үсеш һәм тышкы элемтәләр департаменты директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 29 гыйнвар
№ ПУ-41